| МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

№ 41/о

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«21» 02 2017

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының ведомство бүләкләре турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, "Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында" 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте турында" 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы белән тармакта хезмәттәшлек итүче ведомство оешмалары (учреждениеләре) һәм предприятиеләре хезмәткәрләрен һәм җитәкчеләрен; Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында вазыйфалар биләүче хезмәткәрләрне һәм дәүләт гражданлык хезмәткәрләрен һәм бүтән затларны Татарстан Республикасында төзелешне, архитектураны һәм торак-коммуналь хуҗалыгын үстерүдә хезмәт һәм казанышлар өчен бүләкләү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Түбәндәге кушымталарны расларга:

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының Мактау грамотасы турында нигезләмә;

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының Рәхмәт хаты, Рәхмәте турында нигезләмә;

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының Мактау грамотасы бланкына тасвирлама;

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының Рәхмәт хаты бланкына тасвирлама;

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының Рәхмәт бланкына тасвирлама.

2. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю. Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен әлеге боерыкның билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы җитәкчесе Г.С. Миңнехановага әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр И.Ә.Фәйзуллин

МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ
ОТДЕЛ ОРГАНИЗАЦИОННО-ПРОТОКОЛЬНОЙ РАБОТЫ, КОНТРОЛЯ И ДЕЛОПРОИЗВОДСТВА

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 28.02. №41/о боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының Мактау грамотасы турында
нигезләмә

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының Мактау грамотасы (алга таба – Мактау грамотасы) Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының ведомство бүләге булып тора, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык) белән тармакта хезмәттәшлек итүче ведомство оешмалары (учреждениеләре) һәм предприятиеләре хезмәткәрләрен һәм җитәкчеләрен; Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында вазыйфалар биләүче хезмәткәрләрне һәм дәүләт гражданлык хезмәткәрләрен һәм бүтән затларны Татарстан Республикасында төзелешне, архитектураны һәм торак-коммуналь хуҗалыгын (алга таба – тармак) үстерүдәге хезмәте һәм казанышлары өчен бүләкләү максатларында гамәлгә куелды.

2. Мактау грамотасы белән бүләкләнәләр:

Татарстан Республикасы территориясендә тиешле тармакта күп еллык намуслы хезмәт, файдалы һәм нәтиҗәле хезмәт эшчәнлеге, квалификацияле профессиональ кадрлар әзерләгән, дәүләт программаларын тормышка ашырган өчен Министрлык белән тармакта хезмәттәшлек итүче ведомство оешмалары (учреждениеләре) һәм предприятиеләре хезмәткәрләре һәм җитәкчеләре; Министрлык, дәүләт һәм башкарма хакимият органнары, белем бирү йортлары хезмәткәрләре, һәм бүтән затлар;

күп еллык нәтиҗәле дәүләт гражданлык хезмәте өчен Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында вазыйфалар биләүче Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре (алга таба – дәүләт гражданлык хезмәткәрләре).

Мактау грамотасы белән бүләкләү өчен кандидатлар бер үк вакытта түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

тармакта кимендә биш еллык эш стажына ия булу,

кандидатның бүтән бүләкләүләргә ия булуы,

профессиональ казанышлары булу,

алынмаган дисциплинар түләттерүләре булмау,

законнарда билгеләнгән тәртиптә алынмаган яки үтәлмәгән суд хөкемендә булмавы.

3. Мактау грамотасы белән бүләкләү карары Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының дәүләт һәм ведомство бүләкләре белән бүләкләүгә карата тәкъдим гаризаларын

карап тикшерү комиссиясе бәяләмәсе буенча Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министры (алга таба – министр) тарафыннан кабул ителә.

Мактау грамотасы белән бүләкләү министр боерыгы белән рәсмиләштерелә.

4. Оешма хезмәткәрләрен яки коллективын Мактау грамотасы белән бүләкләүгә тәкъдим гаризасын оешма (учреждение) яисә предприятие җитәкчесе җибәрә.

Оешма (учреждение) яисә предприятие җитәкчеләрен Мактау грамотасы белән бүләкләүгә тәкъдим гаризасын югары торучы оешма (холдинг) җитәкчесе яисә территориясендә оешма теркәлгән һәм гамәлдә булган Татарстан Республикасы җирле үзидарә органы җитәкчесе җибәрә.

5. Мактау грамотасы белән бүләкләүгә карата тәкъдим гаризасына кандидатка (соңгы биш ел эчендә тармактагы билгеле бер казанышларын күрсәтеп һәм аның гамәлдәге дициплинар җәзасы барлыгын яисә юклыгын раслап) оешма (учреждение) яисә предприятие җитәкчесенең имзасы белән таныкланган сыйфатлама; кандидатка объектив мәгълүматлар турында белешмә; оешманың (учреждениенең) яисә предприятиенең сан составы турында белешмә теркәлә.

Оешма (учреждение) яисә предприятие коллективын Мактау грамотасы белән бүләкләгәндә соңгы биш ел эчендә коллективның тармактагы билгеле бер казанышларын, соңгы өч елда һәм агымдагы елда оешманың техник-икътисадый күрсәткечләрен күрсәтеп белешмә, оешманың (учреждениенең) яисә предприятиенең барлыкка килү датасын раслый торган документ бирелә.

6. Мактау грамотасы белән бүләкләүгә тәкъдим гаризасы бүләкләүнең күздә тотылган чорына кадәр 30 календарь көненнән дә соңга калмыйча бирелә. Мактау грамотасын әзерләү вакыты – тәкъдим гаризасы Министрлыкта теркәлгән көннән соң бер ай.

7. Мактау грамотасын тапшыру тантаналы шартларда оешма (учреждение) яисә предприятие коллективында министр тарафыннан, яисә аның кушуы буенча, министрның тармакны җитәкләүче урынбасары тарафыннан яисә министр исеменнән оешма (учреждение) яисә предприятие җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8. Мактау грамотасы белән бүләкләнгән затлар бер үк вакытта оешманың (учреждениенең) яисә предприятиенең шәхси чаралары хисабыннан, гамәлдәге норматив-хокукый актлар нигезендә премияләнергә мөмкин.


9. Яңа казанышлар өчен Мактау грамотасы белән бүләкләүгә яңадан тәкъдим итү моннан алда бүләкләүдән соң кимендә биш ел узгач мөмкин.

10. Мактау грамотасы югалган очракта, аның дубликаты бирелми.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 21.02 №41/0 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының Мактау грамотасы бланкына тасвирлама

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының Мактау грамотасы кәгазе Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 9 сентябрендәге ПУ-880 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасының рәсми һәм эш стиле элементларын төзүнең һәм файдалануның визуаль стандартлары паспортына туры китереп, 210x297 мм ( А4 форматы) зурлыгында эшләнде, ак төсле офсет кәгазеннән ясалды, түбәндәгеләрдән файдаланып: Татарстан Республикасы Дәүләт гербының алтынсу төсендәге схематик сурәте, стиль хасил итә торган элемент – алтынсу төсендәге үсемлек орнаменты, алтынсу төсендәге "Тюльпан" модуле белән рамкалар рәвешендәге кысалар, алтынсу һәм кара төсләрдәге Times New Roman Regular шрифты хәрефләре. Бланк А4 форматындагы рамкага куела.


ПОЧЕТНАЯ
ГРАМОТА
МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ
И ЖИЛИЩНО - КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Приказ №
от ________ 20 г.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 21.02. №41/о боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының Рәхмәт хаты, Рәхмәте турында нигезләмә

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының Рәхмәт хаты (алга таба – Рәхмәт хаты) Татарстан Республикасының ведомство бүләге булып тора, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык) белән тармакта хезмәттәшлек итүче ведомство оешмалары (учреждениеләре) һәм предприятиеләре хезмәткәрләрен һәм җитәкчеләрен; Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында вазыйфалар биләүче хезмәткәрләрне һәм дәүләт гражданлык хезмәткәрләрен, һәм бүтән затларны Татарстан Республикасында төзелешне, архитектураны һәм торак-коммуналь хуҗалыгын (алга таба – тармак) үстерүдәге хезмәт һәм казанышлар өчен бүләкләү максатларында гамәлгә куелды.

2. Рәхмәт хаты белән бүләкләнәләр:

Татарстан Республикасы территориясендә тиешле тармакта намуслы хезмәт, файдалы һәм нәтиҗәле хезмәт эшчәнлеге, квалификацияле профессиональ кадрлар әзерләгән, дәүләт программаларын тормышка ашырган өчен Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы белән тармакта хезмәттәшлек итүче ведомство оешмалары (учреждениеләре) һәм предприятиеләре хезмәткәрләре, җитәкчеләре һәм коллективлары; Министрлык, дәүләт һәм башкарма хакимият органнары, белем бирү йортлары хезмәткәрләре, һәм бүтән затлар;

намуслы һәм нәтиҗәле дәүләт гражданлык хезмәте өчен Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында вазыйфалар биләүче Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре (алга таба – дәүләт гражданлык хезмәткәрләре).

Рәхмәт хаты белән бүләкләү өчен кандидатлар бер үк вакытта түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

тармакта кимендә бер еллык эш стажына ия булу,

профессиональ казанышлары булу,

алынмаган дисциплинар түләттерүләре булмау,

законнарда билгеләнгән тәртиптә алынмаган яки үтәлмәгән суд хөкемендә булмавы.

3. Татарстан Республикасында аеруча әһәмиятле һәм катлаулы биремнәрне үтәгән, билгеле бер объектларны сыйфатлы итеп һәм оператив

рәвештә проектлаган һәм төзегән оешмаларның (учреждениеләрнең) һәм предприятиеләрнең хезмәткәрләренә, җитәкчеләренә һәм коллективларына, тиешенчә рәсмиләштерелгән бланкны тапшырып, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгыннан Рәхмәт белдерелергә мөмкин.

3. Рәхмәт хаты белән бүләкләү карары Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының дәүләт һәм ведомство бүләкләре белән бүләкләүгә карата тәкъдим гаризаларын карап тикшерү комиссиясе бәяләмәсе буенча Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министры (алга таба – министр) тарафыннан кабул ителә.

Рәхмәт хаты белән бүләкләү министр боерыгы белән рәсмиләштерелә.

5. Оешма хезмәткәрләрен яки коллективын Рәхмәт хаты белән бүләкләүгә тәкъдим гаризасын оешма (учреждение) яисә предприятие җитәкчесе җибәрә.

Оешмаларның (учреждениеләрнең) яисә предприятиеләрнең җитәкчеләрен Рәхмәт хаты белән бүләкләүгә тәкъдим гаризасын югары торучы оешма (холдинг) җитәкчесе яисә территориясендә оешма теркәлгән һәм гамәлдә булган Татарстан Республикасы җирле үзидарә органы җитәкчесе җибәрә.

6. Рәхмәт хаты белән бүләкләүгә карата тәкъдим гаризасына кандидатка (соңгы биш ел эчендә тармактагы билгеле бер казанышларын күрсәтеп һәм аның гамәлдәге дициплинар җәзасы барлыгын яисә юклыгын раслап) оешма (учреждение) яисә предприятие җитәкчесенең имзасы белән таныкланган сыйфатлама; кандидатка объектив мәгълүматлар турында белешмә; оешманың (учреждениенең) яисә предприятиенең сан составы турында белешмә; Рәхмәт хатының якынча тексты теркәлә.

Оешма (учреждение) яисә предприятие коллективын Рәхмәт хаты белән бүләкләгәндә соңгы биш ел эчендә коллективның тармактагы билгеле бер казанышларын күрсәтеп белешмә, соңгы өч елда һәм агымдагы елда оешманың техник-икътисадый күрсәткечләре, коллективның барлыкка килү датасын раслый торган документ бирелә.

7. Рәхмәт хаты белән бүләкләүгә тәкъдим гаризасы Министрлыкка бүләкләүнең күздә тотылган чорына кадәр 30 календарь көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла. Рәхмәт хатын әзерләү вакыты – тәкъдим гаризасы Министрлыкта теркәлгән көннән соң бер ай.

Рәхмәт хатын тапшыру тантаналы шартларда оешма коллективында министр тарафыннан, яисә аның кушуы буенча, министрның тармакны җитәкләүче урынбасары тарафыннан яисә министр исеменнән оешма (учреждение) яки предприятие җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

9. Рәхмәт хаты белән бүләкләнгән затлар бер үк вакытта, гамәлдәге норматив-хокукый актлар нигезендә, оешмаларның (учреждениеләрнең) яисә предприятиеләрнең шәхси чаралары хисабыннан премияләнергә мөмкин.

10. Яңа казанышлар өчен Рәхмәт хаты белән бүләкләүгә яңадан тәкъдим итү моннан алда бүләкләүдән соң кимендә биш ел узгач мөмкин була.

11. Рәхмәт хаты югалган очракта, аның дубликаты бирелми.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 21.02. № 41/о боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының Рәхмәт хаты бланкына
тасвирлама

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының Рәхмәт хаты бланкы Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 9 сентябрендәге ПУ-880 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасының рәсми һәм эш стиле элементларын төзүнең һәм файдалануның визуаль стандартлары паспортына туры китереп, 210x297 мм ( А4 форматы) зурлыгында ак төсле офсет кәгазеннән ясалды, түбәндәгеләрдән файдаланып: Татарстан Республикасы Дәүләт гербының алтынсу төсендәге схематик сурәте, стиль хасил итә торган элемент – алтынсу төсендәге үсемлек орнаменты, алтынсу төсендәге "Тюльпан" модуле белән рамкалар рәвешендәге кысалар, алтынсу һәм кара төсләрдәге Times New Roman Regular шрифты хәрефләре. Бланк А4 форматындагы рамкага куела.



Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 21.02. №41/о боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы Рәхмәтенә
тасвирлама

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының Рәхмәт бланкы Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 9 сентябрендәге ПУ-880 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасының рәсми һәм эш стиле элементларын төзүнең һәм файдалануның визуаль стандартлары паспортына туры китереп, 210x297 мм ( А4 форматы) зурлыгында ак төсле офсет кәгазеннән ясалды, түбәндәгеләрдән файдаланып: Татарстан Республикасы Дәүләт гербының алтынсу төсендәге схематик сурәте, стиль хасил итә торган элемент – алтынсу төсендәге үсемлек орнаменты, орнаменталь челтәр – алтынсу төсендәге паттерннан рамкалар рәвешендәге кысалар, алтынсу һәм кара төсләрдәге Times New Roman Regular шрифты хәрефләре. Бланк А4 форматындагы рамкага куела.

